**СОВЕТ ТАШЛЫ-КОВАЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422716, Республика Татарстан, Высокогорский район, с.Ташлы-Ковали, ул.Школьная, 94

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТАШЛЫ КАВАЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

422716, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Ташлы-Кавал авылы., Мэктэп ур.,94

тел./факс 8(84365) 70-4-16, e-mail: Tkv.Vsg@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**20 июнь 2024 ел** **№ 87**

## Жирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә ышанычсыз дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясындагы 3 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Ташлы-Ковалы авыл җирлеге Уставы, Ташлы-Ковалы авыл җирлеге Советы нигезендә КАРАР ИТТЕ:

1. 2024 елның 1 гыйнварына аерым салым түләүчеләр өчен саналган җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә ышанычсыз дип тануга өстәмә нигезләр билгеләргә:

1) варислар мираска хокуктан баш тарткан, варислар булмаган яисә мирас ачылган көннән бер ел дәвамында мирас кабул итмәгән очракта үлгән яисә вафат булган физик затларның бурычлары булу;

2) оешмалар яисә индивидуаль эшкуарлар өчен җирле салымнар 2024 елның 1 гыйнварына кадәр юкка чыгарылган бурыч булу;

3) физик затларның Россия Федерациясе Салым кодексының 48 статьясында билгеләнгән сроклар узганнан соң 500 сумнан артмаган суммада бурычы булу.

2. Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә ышанычсыз дип тануның өстәмә нигезләре булуын раслаучы документлар булып тора, дип билгеләргә.:

1) әлеге Карарның 1 пунктының 1 бүлегендә күрсәтелгән нигезләр булганда:

а) физик затның яшәү урыны буенча салым органының бурыч суммасы турында белешмәсе;

б) вафат булуга бәйле рәвештә салым органнарында физик затны исәпкә алудан төшерү турында белешмәләр;

в) мираска хокук турында таныклык бирү турында белешмәләр булмау турында салым органы белешмәсе;

2) әлеге Карарның 1 пунктының 2 пунктчасында күрсәтелгән нигезләр булганда:

а) оешма, индивидуаль эшкуар, индивидуаль эшкуар статусын югалткан физик затны исәпкә алу урыны буенча салым органы белешмәсе, бурыч суммасы турында;

б) салым бетерелгән норматив хокукый акт (исеме, датасы, номеры) турында белешмәләр;

3) әлеге Карарның 1 пунктының 3 бүлегендә күрсәтелгән нигез булганда, - салым органының 500 сумнан артмаган суммада бурыч барлыгы турындагы белешмәсе.

3. Ташлы Кавал авыл җирлеге Советының «Җирле салымнар суммасында бурычны түләтүгә ышанычсыз дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында» 2023 елның 02 июнендәге 60 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында https://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ адресы буенча һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгару (халыкка җиткерү) юлы белән бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Совет рәисе
Ташлы Кавал авыл җирлеге башлыгы И.И.Хайбуллин